# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы
Лебедино авыл җирлеге Лебедино авыл торак пунктында гражданнар
җыены нәтиҗәләре турында

**2022 елның 13октябреннән** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясынигезендә 2022 елның 13октябрендә12:00,16:00 сәгатьләрдә узган гражданнар җыенының нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде, түбәндәге сорау буенча «Сез 2023 елда Алексеевск муниципаль районының «Лебедино авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендәге Лебедино авыл торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1400 сум күләмендә үзара салым кертү белән килешәсезме, 1 төркем инвалидлардан,көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына сроклы хезмәткә алынучы гражданнардан тыш, һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә сез ризамы:

- янгын сүндерү машинасын карап тоту;
- Лебедино мәдәният йорты өчен музыка аппаратурасы сатып алу;
- урамнарны яктыртуны карап тоту;
- техниканы-тракторны карап тоту;
- юлларга таш җәю;
- су насосларын сатып алу;
- янгын гидрантларын урнаштыру;
- зиратка гыйбадәткылу урынын кую;

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукы булган 331кеше кертелгән, гражданнар җыенында тавыш бирүдәк атнашкан гражданнар саны 193 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышы түбәндәгечә бүленде:

«ЯКЛЫЙМ» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашкан 192 кеше тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен 1 җыенда катнашучы тавыш бирде.

Бәя нителгәннәр нигезендә гражданнар җыены хәлитте:

1. Алексеевск муниципаль районы Лебедино авыл җирлегендәге Лебедино авыл торак пунктында гражданнар җыены булып узды дип танырга, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип таныргa.
2. Сорау буенча карарны кабул ителгән дип таныргa: «Сез 2023 елда Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Лебедино авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендәге Лебедино авыл торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1400 сум күләмендә үзара салым кертү белән килешәсезме, 1 төркем инвалидлардан, көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына срокль хезмәткә алынучы гражданнардан тыш, һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә сез ризамы:

- янгын сүндерү машинасын карап тоту;
- Лебедино мәдәният йорты өчен музыка аппаратурасы сатып алу;
- урамнарны яктыртуны карап тоту;
- техниканы-тракторны карап тоту;
- юлларга таш җәю;
- су насосларын сатып алу;
- янгын гидрантларын урнаштыру;
- зираткагый бадәткылу урынын кую;

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен , кабул ителгән көннән 10 көн эчендә Лебедино авыл җирлеге мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә , Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында (http:// alekseevskiy.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Лебедино авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Алексеевск муниципаль районы
Лебедино авыл җирлеге башлыгы ____________ Тюкарев Ю.И.
(имза ) (имзаның расшифровкасы)